| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

03.11.2017 Казан ш. № 5-12/тэ

2018 елга җылы белән тәэмин итүче оешмалар тарафыннан кулланучыларга, җылы белән тәэмин итүче бүтән оешмаларга җиткерелә торган җылылык энергиясенә (куәтенә) тарифлар билгеләү хакында

«Җылы белән тәэмин итү турында» 2010 елның 27 июлендәге 190-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Җылы белән тәэмин итү өлкәсендә бәя хасил итү турында» 2012 елның 22 октябрендәге 1075 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Җылы белән тәэмин итү өлкәсендә җайга салынулы бәяләрне (тарифларны) хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 13 июнендәге 760-э номерлы боерыгы, Россия Федерациясе Энергетика министрлыгының «2029 елга кадәр Казан шәһәрен җылы белән тәэмин итү схемасын раслау турында» 2015 елның 13 мартындагы 130 номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Сухарево авыл җирлеге Башкарма комитетының «Җылы белән тәэмин итү схемасын раслау турында» 2014 елның 02 декабрендәге 85 номерлы, Түбән Кама муниципаль районының Ширәмәт авыл җирлеге Башкарма комитетының «Җылы белән тәэмин итү схемасын раслау турында» 2014 елның 26 ноябрендәге 99 номерлы карарлары нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Шушы карар кушымтасына туры китереп, җылы белән тәэмин итүче оешмалар тарафыннан кулланучыларга, җылы белән тәэмин итүче башка оешмаларга җиткерелә торган җылылык энергиясенә (куәтенә) календарь буенча бүлгәләнгән тарифлар билгеләргә.

2. Шушы карарның 1 пунктында билгеләнгән тарифлар 2018 елның 1 гыйнварыннан башлап 2018 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис М.Р.Зарипов

Татарстан Республикасы
Тарифлар буенча дәүләт комитетының
03.11.2017 № 5-12/тэ карарына кушымта

## 2018 елга җылы белән тәэмин итүче оешмалар тарафыннан кулланучыларга, җылы белән тәэмин итүче башка оешмаларга җиткерелә торган җылылык энергиясенә (куәтенә) календарь буенча бүленгән тарифлар

| № п/п | Муниципаль берәмлекнең, җайга салучы оешманың аталышы, тариф төре | Ел | Су | Басым белән сайлап алынган пар | | | | Әче һәм редуцияләштерелгән пар |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 1,2 башлап 2,5 кг/см2 кадәр | 2,5тән 7,0 кг/см2 кадәр | 7,0дән 13,0 кг/см2 кадәр | югары 13,0 кг/см2 | |
| | Түбән Кама муниципаль районы | | | | | | | |
| 1 | «БРИГ» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте | | | | | | | |
| 1.1 | Тоташтыру схемасы буенча тарифлар дифференциацияләнмәгәндә, – кулланучылар өчен | | | | | | | |
| | бер ставкалы, сум/Гкал | 01.01.2018 башлап 30.06.2018 кадәр | 2032,55 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2018 башлап 31.12.2018 кадәр | 2112,85 | - | - | - | - | - |
| 2 | «Шереметьевский ЖилСтройСервис» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте | | | | | | | |
| 2.1 | Тоташтыру схемасы буенча тарифлар дифференциацияләнмәгәндә, – кулланучылар өчен | | | | | | | |
| | бер ставкалы, сум/Гкал | 01.01.2018 башлап 30.06.2018 кадәр | 1919,27 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2018 башлап 31.12.2018 кадәр | 1994,52 | - | - | - | - | - |
| | Казан шәһәре | | | | | | | |
| 3 | “Идел-Чулман фәнни-тикшеренү һәм конструкторлык-технологик су урман транспорты институтының тәҗрибә-җитештерү заводы” җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте | | | | | | | |
| 3.1 | Тоташтыру схемасы буенча тарифлар дифференциацияләнмәгәндә, – кулланучылар өчен | | | | | | | |
| | бер ставкалы, сум/Гкал | 01.01.2018 башлап 30.06.2018 кадәр | 1258,38 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2018 башлап 31.12.2018 кадәр | 1307,89 | - | - | - | - | - |
| 3.2 | Халык (тарифлар НДС исәпкә алып күрсәтелде)* | | | | | | | |
| | бер ставкалы, сум/Гкал | 01.01.2018 башлап 30.06.2018 кадәр | 1484,89 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2018 башлап 31.12.2018 кадәр | 1543,31 | - | - | - | - | - |
| 4 | «Теплоконтроль» акционерлык җәмгыяте | | | | | | | |
| 4.1 | Тоташтыру схемасы буенча тарифлар дифференциацияләнмәгәндә, – кулланучылар өчен | | | | | | | |
| | бер ставкалы, | 01.01.2018 башлап | 1637,15 | - | - | - | - | - |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | сум/Гкал | 30.06.2018 кадәр | | | | | | |
| | | 01.07.2018 башлап 31.12.2018 кадәр | 1702,26 | - | - | - | - | - |

<*> Россия Федерациясе Салым кодексының 168 статьясының 6 пунктын үтәү максатларында аерып чыгарыла

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт
комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне
оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге